**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

2013 ел, 6 август г.Казань **№** 01-02/84

Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлеген раслау турында

“Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында” 2012 елның 25 декабрендәге 91-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын һәм “Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру буенча вәкаләтле орган турында” 2013 елның 24 июнендәге 436 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарының 4 пунктын үтәү йөзеннән, боерам:

1. Татарстан Республикасы Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең тәкъдимнәрен кабул итәргә һәм Татарстан Республикасы Казан муниципаль районы территориясендә иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннарның әлеге исемлеген расларга.
2. Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлегенә (Аверьянова Э.М.) әлеге Боерыкны дәүләт теркәвенә алырга.
3. Закон проектлары белән эшләү бүлегенә (Кәримова А.Р.) әлеге Боерыкны татар теленә тәрҗемә итүне тәэмин итәргә.
4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә (Сафин А.Г.), Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының бердәм банкы бүлеге (Аверьянова Э.М.) белән берлектә әлеге Боерыкны татар һәм рус телләрендә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының хокукый мәгълүмат рәсми сайтында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга (бастырып чыгарырга).
5. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы юстиция министры урынбасары - Хокук мәсьәләләре буенча җирле үзидарә

органнары белән хезмәттәшлекне оештыру департаменты башлыгы М. М.Ибәтовка йөкләргә.

Министр М.М. Корманов

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2013 елның 6

августындагы 01-02/84 номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Казан шәһәре территориясендәге иҗтимагый әһәмияткә ия мәсьәләләр буенча коллектив фикер алышу һәм иҗтимагый халәтне чагылдыру, шулай ук иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль мәсьәләләр буенча иҗтимагый фикерне белдерү өчен гражданнарның массакүләм катнашуы өчен каралган бердәй махсус билгеләнгән яки махсуслаштырылган урыннар исемлеге

| № п/п | Муниципаль берәмлек исеме | Махсус билгеләнгән урын адресы | Махсус билгеләнгән урын тасвирламасы |
|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре (Администрация Киров һәм Мәскәү районнары администрациясе) | Татарстан Республикасы, Казан шәһ., Богатырев ур. | Богатырев урамы буенча урнашкан Петров паркындагы барельеф композициясе янындагы территория |
| 2 | Казан шәһәре (Совет районы администрациясе) | Татарстан Республикасы, Казан шәһ., Дәрвишләр бистәсе, Совет ур., 18 йорт | Совет ур., 19, 21 йортлар янындагы территория |
| 3 | Казан шәһәре (Авиатөзелеш һәм Яңа-Савин районнары администрациясе) | Татарстан Республикасы, Казан шәһ., Копылов ур. | Копылов урамы буенча “Крылья Советов” паркындагы В.И. Ленин һәйкәле янындагы территория |
| 4 | Казан шәһәре (Вахитов һәм Идел буе районнары администрациясе) | Татарстан Республикасы, Казан шәһ., Татарстан ур., 53 йорт | Татарстан урамы буенча Кәрим Тинчурин исемендәге скверлагы фонтан янындагы территория. |